ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ ГОРОДА
ИННОПОЛИС

ул. Спортивная, д.114, г.Иннополис,
Верхнеуслонский район,
Республика Татарстан, 420500

ИННОПОЛИС
ШӘҺӘРЕНЕҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Спортивная ур., 114-нче йорт, Иннополис
шәһәре, Югары Ослан районы, Татарстан
Республикасы, 420500

тел. (843) 212-27-24, e-mail: city@innopolis.ru, www.verhniy-uslon.tatarstan.ru/rus/innopolis.htm

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

07.12.2022 Иннополис шәһәре 91

«Иннополис шәһәре Башкарма комитеты ихтыяҗлары өчен сатып алуларны гамәлгә ашыру буенча бердәм комиссия төзү турында» Иннополис шәһәре Башкарма комитетының 2016 елның 5 апреленнән 08 карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 05 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон, «Юридик затларның аерым төрләре тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар турында» Федераль законның 3 статьясына һәм «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» Федераль законның 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 11 июнендәге 160-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Иннополис шәһәре Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Иннополис шәһәре Башкарма комитетының .2016 елның 5 апреленнән карары белән расланган Иннополис шәһәре Башкарма комитеты ихтыяҗлары өчен товарлар (эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү) белән тәэмин итүчеләрне (подрядчыларны, башкаручыларны) билгеләү өчен конкурслар, аукционнар һәм котировкалар уздыру буенча бердәм комиссия турындагы Нигезләмәнең 4.5 пунктына үзгәрешләр кертергә

«6. Комиссия әгъзалары була алмый:

- сатып алуны гамәлгә ашыру турында хәбәрнамәне, сатып алу турындагы документларны (әлеге Федераль закон сатып алу турындагы документлар каралган очракта), конкурста катнашуга заявкаларны эксперт бәяләүне үткәрүгә экспертлар буларак җәлеп ителгән физик затлар;

- тәэмин итүчене (подрядчыны, башкаручыны) билгеләү нәтиҗәләрендә шәхси кызыксынуы булган физик затлар, шул исәптән тәэмин итүчене (подрядчыны, башкаручыны) билгеләүдә катнашуга гариза биргән физик затлар, яки заявкалар

биргән оешмалар яисә физик затлар белән хезмәт мөнәсәбәтләрендә торучы, яки тәэмин итүчене (подрядчыны, башкаручыны) билгеләүдә катнашуга гариза биргән идарәче оешмалар булган затлар;

- сатып алуда катнашуга заявка биргән оешмаларның катнашучылары (акционерлары) булган физик затлар, аларның идарә органнары әгъзалары, закупкада катнашучыларның кредиторлары;

- «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 05 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 99 статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән контроль органнарының вазыйфаи затлары сатып алулар өлкәсендә турыдан-туры контрольне гамәлгә ашыра.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә (http://verhniy-uslon.tatarstan.ru) Иннополис шәһәре Мэриясе бинасында урнашкан махсус мәгълүмат стендында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче И.Р. Хуззятов